ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.11.2022 ел с.Ямбулатово № 2

Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяр авылында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 19 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Казыльяр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 6800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

- Казыльяр авылына юл салу өчен вак таш сатып алу һәм кайтару.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Казыльяр авылы, Урман урамы, 28 номерлы торак йорт янында 9.00 сәгатьтә.

4. Ямбулат авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы А.Н.Макаров